| Республика Татарстан | Татарстан Республикасы |
|---|---|
| Менделеевский муниципальный район | Менделевск муниципаль районы |
| Исполнительный комитет | Турай авыл җирлеге |
| Тураевского сельского поселения | башкарма комитеты |

**Постановление** **Карар**

**№23** **2020 елның 16 июленнән**

Адресларны бирү, үзгәртү һәм юкка чыгару буенча
муниципаль хезмәт күрсәтүнең
административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

"Дәүләт муниципаль хезмәтләре күрсәтүне оештыру турында" 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законны гамәлгә ашыру максатларында Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Турай авыл җирлеге башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының Турай авыл җирлеге башкарма комитетының 2020 елның 21 февралендәге 5 номерлы карары белән расланган Агач һәм куакларны кисүгә, кронировкалауга яисә утыртуга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Административ регламентның 1.5 пунктының 3 абзацын үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә::

«адрес - Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыру принциплары нигезендә структуралаштырылган һәм шул исәптән урам-юл челтәре элементының исемен һәм (яисә) планлаштыру структурасы элементының исемен (кирәк булганда), шулай ук адресация объектын идентификацияләү мөмкинлеген бирә торган цифрлы һәм (яисә) хәрефле-цифрлы билгесен үз эченә алган адрес объектының урнашкан урынын тасвирлау;

1.2. Административ регламентның 1.5 пунктындагы 5 абзацын үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«адресация объекты - капиталь төзелеш объекты, җир кишәрлеге яки Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән адресация объектлары исемлегендә каралган башка объект;»

1.3. Административ регламентның 1.5 пунктындагы 10 абзацын үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«планировка структурасы элементы - зона (массив), район (шул исәптән торак район, микрорайон, квартал, сәнәгать районы), гражданнарның үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык яисә яшелчәчелек белән шөгыльләнү территориясе;»

1.4. Административ регламентның 2.15 пунктындагы 13 абзацын үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | |
|---|---|---|
| 2.15. Муниципаль хезмәтнең ачыклыгы һәм сыйфаты күрсәткечләре, шул исәптән мөрәҗәгать итүченең вазыйфаи | Муниципаль хезмәт күрсәтүнең һәркем өчен мөмкин булуы күрсәткечләре булып тора:<br><br>бина җәмәгать транспортыннан файдалану мөмкинлеге зонасында урнашкан; | |

| | | |
|---|---|---|
| затлар белән муниципаль хезмәт күрсәткәндә үзара хезмәттәшлеге саны һәм аларның дәвамлылыгы, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәгендә муниципаль хезмәт алу мөмкинлеге, читтән торып эшли торган эш урыннарында дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәге, муниципаль хезмәт күрсәтү барышы турында, шул исәптән мәгълүмат-коммуникация технологияләрен кулланып, мәгълүмат алу мөмкинлеге | кирәкле белгечләр саны, шулай ук гариза бирүчеләрдән документлар кабул итела торган бүлмәләр булу;<br><br>«Интернет» челтәрендәге мәгълүмат стендларында, мәгълүмати ресурсларда, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталында Муниципаль хезмәт күрсәтү ысуллары, тәртибе һәм сроклары турында тулы мәгълүмат булу.<br><br>инвалидларга, башка затлар белән беррәттән, хезмәт алырга комачаулаучы каршылыкларны җиңүдә ярдәм күрсәтү..<br><br>Муниципаль хезмәт күрсәтүнең сыйфаты түбәндәгеләрнең булмавы белән характерлана:<br><br>мөрәҗәгать итүчеләргә документлар кабул иткәндә һәм биргәндә чиратлар;<br><br>муниципаль хезмәт күрсәтү сроклары бозылганда;<br><br>муниципаль хезмәт күрсәтүче муниципаль хезмәткәрләрнең гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата шикаятьләр;<br><br>муниципаль хезмәт күрсәтүче муниципаль хезмәткәрләрнең мөрәҗәгать итүчеләргә карата дөрес булмаган, игътибарсыз мөнәсәбәтенә шикаятьләр.<br><br>Муниципаль хезмәт күрсәтү турындагы запросны биргәндә һәм муниципаль хезмәт нәтиҗәсен алганда, муниципаль хезмәт күрсәтүче вазыйфаи затның һәм мөрәҗәгать итүченең үзара хезмәттәшлеге күздә тотыла. Хезмәттәшлек дәвамлылыгы регламент белән билгеләнә.<br><br>Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәгендә (алга таба – КФҮ) муниципаль хезмәт күрсәткәндә, КФҮнең ерак эш урыннарында консультацияләр, документларны кабул итү һәм бирү буенча КФҮ белгече башкара.<br><br>Муниципаль хезмәт күрсәтүнең барышы турында мәгълүмат гариза бирүче тарафыннан дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең бердәм порталында, КФҮтә, мөрәҗәгать итүче тарафыннан алынырга мөмкин. | |

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында www.mendeleevsk.tatar.ru «Турай авыл җирлеге» бүлегендә һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Турай авыл җирлеге
Башлыгы А.М.Рәхимова